


## = Вышитые золотом

А лтын белән чигелгән бәрхет калфак лар Казан хатын-кызларының баш киемнәре арасында стильләштерү һәм чигеш сыйфаты ягыннан иң нәфисе, иң затлысыдыр, мөгаен.

Алар алтын яки көмеш ука, кайвакыт алтын җеп белән чигелгән. Ука — үрелгән бик нечкә тимерчыбыклардан гыйбарәт. Борынг>1 укалар затлы металлдан — алтын-көмештән яки элек- труннан (алтын белән көмеш эретмәсеннән) ясалган. Уканы кирәк кадәр озынлыкта кисеп алып, энә-җеп белән калфакка беркетеп куйганнар. Ул туры- дан-туры бәрхет өстенә яки берәр җирлеккә (катыргы, кәгазь, мамык) чигелгән. Җирлеккә беркеткәндә каба- ⁚ рып торган рельефлы чигеш барлыкка килгән. Казан осталары алтынлап чигүнең бик күп гаҗәеп серләрен белгән, ул алымнарның кайберләре башка халыкларда бөтенләй очрамый.

Казан калфакларындагы укалар декоратив элементлар — һәртөрле ялтыравык, җиз тәңкәләр белән баетылган. Нигездә, ирекле булган композицион төзелеш ягыннан да бәрхет калфаклар гаҗәеп камил. Биредә чәчәк-үсем- лек орнаментлары өстенлек итә. Алтын каурый, ай-йолдыз, чәчәк бәйләмнәреннән төрле-төрле композицияләр, тормыш агачы, парлы кошлар — болар иң киң таралган чигү үрнәкләре. Алтын белән чигелгән тегe яки бу бизәк төрле чыганаклардан килгән. Парлы үрдәкләр яки күгәрченнәр — болгар мәдәнияте мирасы. Болгарларга исә ул фин-угырлардан күчкән. Алтын каурый, ай-йолдыз — халык авыз иҗаты: борынгы җырлар, бәетләр белән тыгыз бәйле. Чәчәк бәйләме үрнәге, мөгаен, Иреннан, Төркиядән килгән тукымалардан күчкәндер. Табигый, читтән кергән орна ментлар иҗади эшкәртелеп, милли үзенчәлекле төс алган һәм диңгез аръягындагы кыргый чәчәкләр безнең җирдә үскән гөлләргә охшап калган.

Алтын белән чигелгән казан калфагының бизәгенә стильләштерү хас. Нәфис үсемлек-чәчәк элементлары җай гына берәр бәйләмгә яки "алтын каурыйга" берләшә. Төгәл симметрик композицияләр очрамый диярлек. Үзара бик табигый ярашкан вак һәм эре бизәкләрдән торган орнамент, гадәттә, калфакның өске өлешен каплый. Кайвакыт вак чәчәк бәйләмнәре, калфакның бөтен җирен тутырып, шахмат тәртибендә урнаша, ә фриз (аскы кайма) шул ук чәчәк-үсемлек элементларыннан торган тасмалы орнамент белән тулыландырыла.

**Луиза ФӘСХЕТДИНОВА,**
рәссам, чигү остасы.

Сөембикә – 2008 - №5. – титульный лист.